| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

---

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

23.12.2025 № 1154-р

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУның штат расписаниесенә үзгәреш кертү һәм хезмәткә түләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 01 февралендәге 60-р номерлы күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнехановның 2026 елның 01 гыйнварыннан бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турындагы карарына (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2025 елның 27 октябрендәге 03-12/7278 номерлы хаты), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районында муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары җитәкчеләренә һәм белгечләренә, баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2023 елның 31 гыйнварындагы 91 номерлы карарына ярашлы рәвештә (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 16.08.2024 № 949, 07.11.2024 № 1346, 30.04.2025 № 471, 17.12.2025 №1482 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

БОЕРЫК БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлекләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУның штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү һәм хезмәткә

түләү турындагы нигезләмәне раслау турында» 01.02.2023 ел, № 60-р күрсәтмәсенә 1 нче кушымтага үзгәрешләр кертергә (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 21.09.2023 ел, №573-Р), 23.08.2024 № 470-Р, 17.01.2025 №9-р, 07.05.2025 №520-Р, 28.10.2025 №995-Р боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән), «Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлекләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең штат расписаниесен яңа редакциядә кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге күрсәтмә рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин